**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.05.2017 пгт. Рыбная Слобода № 88пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 1 июлендәге 186пи номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы эшчәнлеге өлкәсенә караган объектларны (территорияләрне) террорчылыкка каршы яклауга карата таләпләрне һәм әлеге объектларның (территорияләрнең) куркынычсызлык паспортының формасын раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 410 номерлы, «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы объектларының (территорияләренең) һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы эшчәнлеге өлкәсенә караган объектларның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы якланганлыгына таләпләрне һәм әлеге объектларның (территорияләрнең) иминлек паспортының формасын раслау турында» 2017 елның 13 гыйнварындагы 8 номерлы, «Мәдәният өлкәсендә объектларны (территорияләрне) террорчылыкка каршы яклауга таләпләрне һәм әлеге объектларның (территорияләрнең) куркынычсызлык рәвешен раслау турында» гы 2017 елның 11 февралендәге 176 номерлы карарларын бастырып чыгаруга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеген төгәлләштерү һәм корректировкалау максатыннан, «Терроризмга каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон , «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 6.1 пункты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең«Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле кешеләрнең һәм объектларның

(территорияләрнең) террорчылыкка каршы яклануына карата таләпләрне һәм мондый урыннар һәм объектларның (территорияләрнең) куркынычсызлыгы паспортларын раслау турында» гы 25.03.2015 елның 25 мартындагы, №272 карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 1 июлендәге 186пи номерлы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 28 мартындагы 42пи номерлы, 2016 елның 23 июнендәге 99пи номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннар исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3,6 һәм 31 пунктларны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин